Татарстан Республикасы

Аксубай муниципаль районы

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

2020 елның 5 ноябре № 7

## Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Яңа аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Аксубай муниципаль районы КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Федоровка Яңа Аксубай авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Федоровский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

**1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш сатып алу;

- торак пункт чикләрендә юл полотносын төзү, шул исәптән туфрак күтәрү, грейдирование, вак таш сибү, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-торак пункт эчендәге юлларны кышын карап тоту, шул исәптән: грейдирование, кардан арындыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

**2 Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.**

- Федоровский торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга обелиск төзү (төзелеш материалы сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.Татарстан Республикасы Аксубай районының Федоровский поселогының үзәк урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

4.Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда игъланнар такталарында элү юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

Аксубай муниципаль районы А.В.Макаров